РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ
ТЕТЮШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422370 г.Тетюши, ул. Малкина, 39
422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур., 39
тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702080, ОГРН 1061672000026, ИНН/КПП 1638004985/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19.02.2020 № 90

**«Тәтеш шәһәреннән 11 км ераклыкта урнашкан аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 18 декабрендәге 587 нче номерлы карарының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында**

«Конкуренцияне яклау турында»гы 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасы район үзәкләреннән 11 км ераклыкта урнашкан Татарстан Республикасының ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 20 ноябрендәге 887 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 28 декабрендәге 1228 нче номерлы карары нигезендә Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Тәтеш шәһәреннән 11 км ераклыкта урнашкан аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле кулланучылар

кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 18 декабрендәге 587 нче номерлы карарының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәгечә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә торуны үз өстемә алам.

**Тәтеш муниципаль районы**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **А.Б. Семенычев**

Тәтеш муниципаль районы
башкарма комитетының
2019 елның 19 февралендәге
90 нчы номерлы карарына
1 нче кушымта

Тәтеш шәһәреннән 11 км ераклыкта урнашкан аз халыклы авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Тәтеш муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Тәтеш шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан авыл торак пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен Тәтеш муниципаль районы бюджеты хисабына каплау тәртибен билгели.

1.2. Субсидияләр Тәтеш муниципаль районы бюджетында каралган чаралар чигендә Тәтеш шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан авыл торак пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерүгә бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга бирелә.

## 2. Субсидияләр бирү максатлары, шартлары һәм тәртибе

2.1. Субсидия бирүнең максаты булып, Тәтеш муниципаль районы составына керүче, авыл торак пунктларында яшәүче авыл халкын «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә беренче чиратта кирәкле товарлар белән тәэмин итү тора.

2.2. Субсидия алучылар булып сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы кулланучылар кооперациясе оешмасы (алга таба - алучы) тора.

2.3. Субсидия бирү шартлары булып тора:

- алучының сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

- азык-төлек продуктларын ташу өчен транспорт чаралары булу;

- Тәтеш муниципаль районының авыл торак пунктларына товарларны атнага 1-4 тапкыр китерүне тәэмин итү;

- үзгәртеп кору, бетерү яки банкротлык стадиясендә тормау.

2.4. Алучы тарафыннан беренче чиратта кирәкле товарларны китерү буенча ягулык материалларына транспорт чыгымнары кайтарылырга тиеш.

2.5. Субсидия алу өчен, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетының социаль-икътисади һәм территориаль үсеш бүлегенә түбәндәге документлар комплектын тәкъдим итәргә кирәк:

- субсидия алуга гариза;

- юридик затның дәүләт теркәвен алу турында таныклык яисә юридик затларның бердәм дәүләт реестрына кертү турында алучы тарафыннан раслаган таныклык күчермәсе;

- транспорт чаралары булуын раслаучы документлар (техник чара паспортының күчермәләре һ.б.);

- беренче чиратта кирәкле продуктларны һәм товарларны транспортлауга кирәкле ягулык материаллары сатып алу чыгымнарын исәпләү (беренчел документацияне кушымта итеп биреп).

2.6. Алучы һәм Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты арасында әлеге тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә төзелгән килешү субсидияне күчерү өчен нигез булып тора.

2.7. Субсидия бирү турындагы килешү буенча йөкләмәләр үтәлмәгән очракта, шулай ук тапшырылган документларда дөрес булмаган яисә тулы булмаган мәгълүмат булган очракта, субсидия Тәтеш муниципаль районы бюджетына кайтарылырга тиеш. Субсидия алучы Тәтеш муниципаль районы башкарма комитетыннан субсидияне кире кайтару турындагы таләпне алган көннән алып 15 (унбиш) көн эчендә акчаларны кире кайтарырга тиеш. Субсидияләрне бюджетка кайтару турындагы таләп үтәлмәгән очракта, субсидия алучы Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җавап бирә.

Субсидия алучы тарафыннан субсидияләр таләптә күрсәтелгән срок эчедә ирекле кире кайтарылмаса, Тәтеш муниципаль районы башкарма комитеты субсидия алучыдан субсидияләр суммасын Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

2.8. Субсидияләр бирү турындагы килешүгә кертелгән субсидияләр бирүнең мәҗбүри шарты булып, аларны алучыларның субсидияләр биргән бюджет акчаларын баш бүлүче һәм Тәтеш муниципаль районының муниципаль финанс тикшерүе органнары тарафыннан субсидия алучыларның субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүләрен тикшерү тора.

2.9. Субсидия алучы тапшырылган документларның законнарда билгеләнгән тәртиптә үз вакытында тапшырылуы һәм дөреслеге өчен җаваплы.

2.10. Хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр суммалары, субсидия бирү турындагы килешүдә каралган очракларда, субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында тиешле бюджетка кире кайтарылырга тиеш.